# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

**(IV чакырылыш)**

IV чакырылышның чираттан тыш утырышы

# КАРАРЫ

25 июнь 2025 ел № 28 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 30.04.2025 № 19 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы район Советы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт транспортыннан һәм ягулык карталарыннан файдалану турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 08 ноябрендәге № 259-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, бюджет акчаларын рациональ тоту, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының хезмәт транспортыннан файдалануын тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 30.04.2025 № 19 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы район Советы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт транспортыннан һәм ягулык карталарыннан файдалану турындагы нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 пунктындагы 3.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Автомобильдән шәхси максатларда, ә автомобильдән эш вакыты билгеләнгән тәмамланганнан соң, ял һәм бәйрәм көннәрендә әлеге Нигезләмәнең 1 пункты һәм башлыкның йә җитәкченең тиешле күрсәтмәсе нигезендә килештерелмичә хезмәт максатларында файдалану тыела.»;

1.2. Нигезләмәнең 4 пунктындагы 4.12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.12. Ягулык картасын шәхси максатларда, ә ягулык картасын билгеләнгән эш вакытытәмамланганнан соң, ял һәм бәйрәм көннәрендә әлеге Нигезләмәнең 1

пункты һәм башлыкның йә җитәкченең тиешле күрсәтмәсе нигезендә килештермичә хезмәт максатларында куллану тыела.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Р.М. Якупов
2-42-05